РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«29» март 2023г. г. Альметьевск № 207

Татарстан республикасы дәүләт
вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен
җаваплы органны билгеләү турында

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына алкоголь, наркотик яисә башка токсик исерек хәлдә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2017 елның 10 июлендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып,

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Башкарма комитетын алкоголь, наркотик яисә башка токсик исереклек халәтендәге затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җаваплы орган итеп билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесен алкоголь, наркотик яисә башка токсик исереклек халәтендәге затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җаваплы дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка җиткергәннән соң) үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Хамадьяров Р.Р.).

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘЛМӘТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
«СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА»